Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы

КАРАРЫ

31 май 2018 ел №122

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территоритясендә җир налогы турында”гы 116 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль Законның 14 маддәсе, Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлеге икенче өлеше, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Уставының 29 маддәсе нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 2 октябрендәге №141, 2014 елның 19 ноябрендәге №151, 2015 елның 6 маендагы №179, 2015 елның 20 ноябрендәге №13, 2016 елның 8 ноябрендәге №49 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 11нче абзацны өстәргә:

- «Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен хәрби-хисап белгечлекләре буенча белгечләр әзерләүне гамәлгә ашыручы автодромнар һәм автомәктәп укыту-матди базасы алып торган җир кишәрлекләренә карата 0,5 процент»;

- 11 абзацны 12 дип санарга.

2. Район башкарма комитеты хокук идарәсе башлыгына (Шәйхулова Ф.Х.) әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU ) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны бюджет-финанс мәсьәләләре буенча шәһәр Советының даими комиссиясенә (Ф.Р. Хәмидуллин) йөкләргә.

Шәһәр башлыгы А.Р. Хәйруллин